**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 11 ноябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Шөн авылы, Октябрь урамы, 22а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 23 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Шөн авылы, Октябрь урамы, 22а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Шөн авылында Чапаев, Октябрь, Май, урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Шөн авылында Октябрь урамыннан Май урамына чыгу юлын ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Югары Шөн авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Югары Шөн авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;
- Югары Шөн авылында спорт мәйданчыгын төзекләндерү, спорт һәм балалар җиһазлары һәм инвентарьлары сатып алу һәм урнаштыру: проект - смета документлары;
- Югары Шөн авылына янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылы зиратын ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары;
- Югары Шөн авылында су башнясын һәм суүткәргеч челтәрне карап тоту һәм ремонтлау , проект-смета документлары;

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Важашур авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов